КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 21 апрель г.Казань № 267

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2022 елларда «Мәгариф» милли проектының «һәр баланың уңышы» федераль проекты кысаларында «Кванториум» мобиль технопарклар төзү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2019 ел, 2 июль, 533 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2022 елларда «Мәгариф» милли проектының «Һәр баланың уңышы» федераль проекты кысаларында «Кванториум» мобиль технопарклар төзү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2019 ел, 2 июль, 533 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 14 апрель, 283 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның өченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Төзелә торган «Кванториум» мобиль технопарклары тасвирламасында:

1 бүлекнең егерме бишенче - утыз бишенче абзацларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

3 бүлекнең унсигезенче - егерме дүртенче абзацларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

4 бүлектә:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Проектны гамәлгә ашыру өчен мобиль кванториум эшләгән вакытта агломерациягә урнаштырыла торган җиһазлар күчерелә торган махсус күчмә станция сатып алу планлаштырыла.»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Газель-Некст» (ГАЗ C46R02) дизель двигателе Cummins IsF 2.8s булган тулы металл фургон. Җиде урынлы кабина (йөртүченең урынын да кертеп). Транспорт чарасының озынлыгы - 6 900 мм, биеклеге - 2 620 мм, йөк күтәрү - 2 000 кг, бәясе - 4 211,35 мең сум.»;

бишенче - ундүртенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

5 бүлекнең егерме тугызынчы - утыз бишенче абзацларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

Төзелә торган «Кванториум» мобиль технопарклары тасвирламасына 1 нче кушымтада «Кванториум» - Алабуга мобиль технопаркы эшчәнлеге күрсәткечләре исемлеген үз көчен югалткан дип танырга;

Төзелә торган «Кванториум» мобиль технопарклары тасвирламасына 1 нче кушымтада «Кванториум» - Алабуга мобиль технопаркы эшчәнлегенә операция чыгымнары калькуляциясен үз көчен югалткан дип танырга;

Төзелә торган «Кванториум» мобиль технопарклары тасвирламасына 3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

Төзелә торган «Кванториум» мобиль технопарклары тасвирламасына 4 нче кушымтада «Кванториум» - Алабуга мобиль технопаркы хезмәткәрләре категорияләренең һәм вазыйфаларының якынча исемлеген үз көчен югалткан дип танырга;

Төзелә торган «Кванториум» мобиль технопарклары тасвирламасына 5 нче кушымтада 2 нче пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин